**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.06.2019 Балык Бистәсе штп №203пи

2019 елга гражданнар кеременең максималь күләмнәрен һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарыннан наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 13-ЗРТ номерлы Законына, күрсәтелгән Законга кушымтада бәян ителгән гаиләнең һәрбер әгъзасына яки ялгыз көн күрүче гражданга туры килгән керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз көн күрүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең чик кыйммәтләрен тәгаенләү Методикасына, Россия Төзелеш министрлыгының 2019 елның 1 апрелендәге “2019 елның 2 кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданы бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында” 197/пр номерлы боерыгына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 маддәсенә таянып КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарыннан наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә гражданнарны мохтаҗ дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең 2019 елга түбәндәге максималь күләмнәрен һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз көн күрүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

ялгыз көн итүче граждан өчен – 1 523 610 сум;
ике кешелек гаилә өчен – 1 939 140 сум;
өч кешелек гаилә өчен – 2 493 180 сум;
дүрт кешелек гаилә өчен – 3 324 240 сум;
биш кешелек гаилә өчен – 4 155 300 сум;
алты кешелек гаилә өчен – 4 986 360 сум;
җиде кешелек гаилә өчен – 5 817 420 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык җыелма кеременең

максималь күләме:

ялгыз көн итүче граждан өчен – 26 830 сум 86 тиен;

ике кешелек гаилә өчен – 17 074 сум 18 тиен;

өч кешедән һәм аннан да артык кешедән торган гаилә өчен – 14 695 сум 01 тиен.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм коммуналь-хуҗалык бүлегенә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарыннан наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Кушымта 1

**2019 елга гаиләнең һәрбер әгъзасына яки ялгыз көн күрүче гражданга туры килгән керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз көн күрүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең чик кыйммәтләрен тәгаенләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарыннан наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба – исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, биредә:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт бәясенең чиге;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ –**РФ ның Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган (2019 елның 2 кварталына – 46 170 сум)** торак урыны мәйданының 1 кв.м ының уртача исәп-хисап базар бәясе;

а) бер үзе генә көн итүче граждан өчен:

СЖ = 46170 х 33 = 1 523 610;

б)ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 42= 1 939 140;

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 18 х 3 = 2 493 180;

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 18 х 4 = 3 324 240;

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 18 х 5 = 4 155 300;

ж) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 18 х 6 = 4 986 360;

з) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 46170 х 18 х 7 = 5 817 420.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык җыелма керем күләменең чиге тәгаенләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - [(1 + ПС) - КП]) / (0,25 х РС), биредә:

СЖ – исәп-хисап күрсәткече;

ПС – ай өчен кредит буенча процент ставкасы (9/12);

КП –бөтен кредит срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС –гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 –кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән нисбәте;

а) бер үзе генә көн итүче граждан өчен:

ПД = (0,7 х 1 442 826 х 0,75) / (1 - [(1 + 0,75) - 120]) / (0,25 х1) = 26 830,86;

б)ике кешелек гаиләгә:
ПД = (0,7 х 1 836 324 х 0,75) / (1 - [(1 + 0,75) - 120]) / (0,25 х 2) = 17 074,18;

в) өч һәм аннан да артык кешедән торган гаиләгә:
ПД = (0,7 х 2 360 988 х 0,75) / (1 - [(1 + 0,75) - 120]) / (0,25 х 3) = 14 635,01;